Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Елховой авыл җирлеге башлыгы

КАРАРЫ

01 ноябрь 2019 ел N 2

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль
районы Елховой авыл җирлеге
Елховой авылында гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү һәм алардан
файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын
билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Әлмәт муниципаль районы Елховой авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елның 15 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Елховой авыл җирлегенең Елховой авылында Җәлил, Киров, Нариман, Тукай урамнарында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2019 елның 15 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Елховой авыл җирлегенең Елховой авылында Гагарин, Камал, Колхоз, Татарстан урамнарында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. 2019 елның 15 ноябрендә 17 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Елховой авыл җирлегенең Елховой авылында Горький, Гыйльми, Комсомол, Пионер, Совет урамнарында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының өченче этабын билгеләргә.
4. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Елховой авыл җирлегенең Елховой авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: трактор сатып алу өчен?

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Халык җыены этапларын Елховой авыл мәдәният йорты бинасында, түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы Әлмәт районы, Елховой авылы, Совет урамы, 70 йортта уздырырга.
6. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Елховой авыл җирлегенең Елховой авылында сайлау хокукына ия булган авыл халкының исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.
7. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Елховой авыл башкарма комитетын билгеләргә.

8. Әлеге карарны җыен үткәрү көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, Елховой авылы, Совет урамы, 67 нче йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» челтәрендә урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

9. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткергән) көненнән үз көченә керә.

Елховой
авыл җирлеге башлыгы Д.Р. Хәйрисламова